КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 март г.Казань № 118

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында» 2017 ел, 20 июнь, 399 нчы карары белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәр оештыру турындагы якынча нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында» 2017 ел, 20 июнь, 399 нчы карары белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәр оештыру турындагы якынча нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Гаилә мәктәпкәчә төркеме күпбалалы гаилә яшәгән урында яки буш булган торак урыннарда урнаша, анда Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирүне, аларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирүне, аларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен үтәп, балаларга белем бирү барышын, тукլануны, йокыны оештыру өчен мәйдан бүлеп бирелә.»;

2.7 пунктта:

өченче абзацка «(Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы өченче өлешендә каралган очраклардан тыш);» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацка «(Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы өченче өлешендә каралган очраклардан тыш);» сүзләрен өстәргә;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Гаилә мәктәпкәчә төркемен финанслар белән тәэмин итү күләмен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карары нигезендә билгеләргә тәкъдим ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин